Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
“Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистәсе”
муниципаль берәмлеге башлыгы

КАРАРЫ

01 ноябрь 2019 ел N 6

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы “Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистәсе” муниципаль берәмлеге Тихоновка авылы гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 нчы статьялары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Әлмәт муниципаль районы “Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистәсе” муниципаль берәмлеге Уставының 14.1 статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘ:

1. 2019 елның 25 ноябрендә 17 сәгать 30 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы “Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистәсе” муниципаль берәмлегенең Тихоновка авылының Речная, Маяковский, Елховская, Южная урамнарында, Терешкова урамында (так йортлар) үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. 2019 елның 26 ноябрендә 17 сәгать 30 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы “Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистәсе” муниципаль берәмлегенең Тихоновка авылының Терешкова урамында (җөп йортлар), Луговая, Р.Галеев, Вишневая, Нефтяниклар урамнарында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабын билгеләргә.

3. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының “Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистәсе” муниципаль берәмлегенең Тихоновка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге средстволарны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме: юлларга асфальт җәю, сметалар төзү һәм техник күзәтчелек үткәрү өчен түләү?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Халык җыены этапларын МББУ “Тихоновка төп гомуми белем бирү мәктәбе», бинасында, түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы, Әлмәт районы, Тихоновка авылы, Терешкова урамы, 72 йортта уздырырга.

5. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы “Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистәсе” муниципаль берәмлегенең Тихоновка авылы сайлау хокукына ия булган авыл халкының исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.

6. Халык җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Түбән Мактама бистәсе башкарма комитетын билгеләргә.

7. Әлеге карарны җыен үткәрү көненә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча, Тихоновка авылы торак пункты территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайтының «Интернет» челтәрендә урнаштырырга (халыкка җиткерергә).

8. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка җиткергән) көненнән үз көченә керә.

Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистә башлыгы В.Н. Михайлов